РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

« 31 » декабрь 2020 с. Тюлячи № 614

2021 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы халкы өчен торак хезмәтләренә тарифлар турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2005 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту һәм алар өчен түләү күләмен нигезләү чаралары турында» 2007 елның 09 апрелендәге 250 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 1 гыйнварыннан түбәндәгеләрне расларга һәм гамәлгә кертергә:

- социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен торак урынны карап торган һәм ремонтлаган өчен түләү күләме һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән милекчеләр өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен 1 номерлы кушымта нигезендә;

- район халкы өчен коммуналь хезмәтләргә тарифларны 2 номерлы кушымта нигезендә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең территориаль үсеш һәм инвестицион эшчәнлек буенча урынбасары И.Ә. Миңнегуловка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«31» 12 2020 № 514
карарына 1 номерлы кушымта

2021 елга район халкы өчен торак хезмәтләренә тарифлар

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Үлчәү берәмлеге | Гамәлдә булу периоды 01.01.2021 ел алып 30.06.2021 ел кадәр (сум) | Гамәлдә булу периоды 01.07.2021 ел алып 31.12.2021 ел кадәр (сум) |
|---|---|---|---|
| **Халык өчен** | | | |
| 1. Торак фонды белән идарә итү | м $^2$ | 3,54 | 3,70 |
| 2. Торак бинага агымдагы ремонт | м $^2$ | 3,43 | 3,58 |
| 3. Йорт эчендәге сантехника челтәрләрен агымдагы ремонтлау | м $^2$ | 2,29 | 2,39 |
| 4. Йорт эчендәге газүткәргеч челтәрләргә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт | м $^2$ | 0,35 | 0,37 |
| 5. Йорт эчендәге электр челтәрләрен агымдагы ремонтлау | м $^2$ | 1,30 | 1,36 |
| 6. Су белән тәэмин итүнең гомумйорт системаларын агымдагы ремонтлау | м $^2$ | 0,52 | 0,54 |
| 7. Йорт яны территориясен җыештыру | м $^2$ | 3,74 | 3,90 |
| 8. Дератизация | м $^2$ | 0,12 | 0,13 |

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«31» 12 2020 № 614
карарына 2 номерлы кушымта

## 2021 елга район халкы өчен коммуналь хезмәтләргә тарифлар

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Үлчәү берәмлеге | Гамәлдә булу периоды 01.01.2021 ел алып 30.06.2021 ел кадәр (сум) | Гамәлдә булу периоды 01.07.2021 ел алып 31.12.2021 ел кадәр (сум) |
|---|---|---|---|
| Халык өчен | | | |
| 1. Бер юынуга мунча хезмәте | чел. | 100 | 100 |